# Синтаксик бәйләнеш төрләре темасы буенча тест

*Тат.Шуран урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Шаева Венера Мнахир кызы*



# 1. Тезүле бәйләнешне белдерүче чараны күрсәтегез.

- аныклаучы теркәгечләр
- тезүче теркәгечләр
- аныклау интонациясе
- килеш кушымчалары

# 2. Ияртүле бәйләнешне белдерүче чараны күрсәтегез.

- санау интонациясе
- каршы кую интонациясе
- тезүче теркәгечләр
- бәйлек һәм бәйлек сүзләр


# 3. Җөмлә кайсы мөнәсәбәт нигезендә барлыкка килә?

- хәбәрлекле
- ачыклаулы
- аныклаулы
- һәр өч мөнәсәбәт нигезендә

4. Ачыклаулы мөнәсәбәтне белдерүче чараны күрсәтегез.

- килеш кушымчалары
- зат-сан кушымчалары
- -ныкы/-неке кушымчасы
- хәбәр итү интонациясе





## 5. Хәбәрлекле мөнәсәбәтне белдерүче чараны күрсәтегез.

- аныклаучы теркәгечләр
- сүзләрне кабатлау
- зат-сан кушымчалары
- тезү интонациясе

# 6. Тезүле бәйләнешне табыгыз

- *язгы көн*
- *килдек һәм күрдек*
- *концерт булды*
- *уку башланды*

# 7. Хәбәрлекле мөнәсәбәтне табыгыз

- *безнең авыл*
- *мәкаләне уку*
- *дустымны, Айратны*
- *апа өйдә*

# 8. Ачыклаулы мөнәсәбәтне табыгыз

*1) кичә кайту*

*2) кунаклар кайтты*

*3) абыең бездә*

*4) сабыр, акыллы*





# 9. Аныклаулы мөнәсәбәтне табыгыз

- *аны — якын дустымны*
- *ябалак кар*
- *мактап әйтү*
- *кайткач күрү*

*10. Табигатьне танып белү һәм табигать белән* ***татулыкта, бердәмлектә*** *яшәү – кеше өчен иң югары бәхет. (М. Хәсәнов)* җөмләсендәге аерып бирелгән сүзләр үзара нинди бәйләнештә торалар?

- 1) тезүле бәйләнештә
- 2) хәбәрлекле мөнәсәбәттә
- 3) ачыклаулы мөнәсәбәттә
- 4) аныклаулы мөнәсәбәттә